# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең Надеждино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**30 ноябрь , 2022 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 22 ноябрендә 12 сәгатьтә, 2022 елның 25 ноябрендә 14 сәгатьтә, 2022 елның 30 ноябрендә 12 сәгатьтә, этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

**а) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**

- су башнясы өчен запас тирән насос сатып алу;

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу (килешү буенча);

**б) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- чүплекләр территориясен чистарту;

**в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:**

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 120 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -65, бу 54.2 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 65 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең Надеждино торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

**а) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**

- су башнясы өчен запас тирән насос сатып алу;

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу (килешү буенча);

**б) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- чүплекләр территориясен чистарту;

**в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:**

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Надеждино авыл җирлеге Башлыгы — Е.В.Савельева